ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙКОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21,e-mail:mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__294__ от « 23 »____03_____2018 г.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча
административ регламентларын
раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ санлы Федераль законын гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Ресубликасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында”2010 ел, 2 ноябрь 880 нче санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма Комитетының “Дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 ел, 20 июнь, 1090 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын расларга:

1.Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (кушымта №1);

2.Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 2);

3. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта №3);

4. Муниципаль мөлкәтне оператив идарә хокукында муниципаль оешмаларга, муниципаль казна предприятиеләренә һәм хуҗалык алып бару хокукында унитар предприятиеләргә рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта №4);

5. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 5);

6. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген күчемсез милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 6);

7. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген күчемсез милеккә түләүсез тиз файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ

регламенты (кушымта № 7);

8. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулашу уздырмыйча сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 8)

9. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулашу уздырмыйча арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 9)

10. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион уздырмыйча арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 10)

11. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген шәхси милеккә яки арендага җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар иясенә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 11)

12. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда шәхси милеккә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 12)

13. Дәүләт яки муниципаль милкендә булган һәм шәхси милектә булган җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен кабат бүлеп бирү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 13);

14. Муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген кулланырга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 14);

15. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шәхси милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 15);

16. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга шәхси милеккә (арендага) торак пункт чикләрендә шәхси хуҗалык алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 16);

17. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга шәхси милеккә (арендага) бакчачылык алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 17);

18. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген гражданнарга шәхси милеккә (арендага) бакчачылык – дача хуҗалыгы алып бару өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 18);

19. Хосусый яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) бер категориядән икенче категориягә күчерү хакында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 19);

20. Җир кишәрлеге белән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануны яки җир кишәрлегенә гомерлеккә биләмә буенча күчкән хокукны туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 20);

21. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 21);

22. Муниципаль милектә исәпләнгән күчемсез милек объектлары реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 22);

23. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 23);

24. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә хәзинә эзләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 24);

25. Муниципаль преференцияләр бирелү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 25);

26. Җир кишәрлекләрен бушлай алу хокукына ия булган затларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты(кушымта № 26);

27. Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү буенча күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 27);

28. Муниципаль казнага кергән милекне арендага тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 28);

29. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 29);

30. Элегрәк приватизацияләнгән торак биналарны муниципаль милеккә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 30);

31. Муниципаль реестрга керүче муниципаль милекне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 31);

32. Җир кишәрлеге белән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 32);

33. Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып баручы коммерциячел булмаган оешма әгъзасы булган гражданнарга җир кишәрлеген бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 33);

34. Муниципаль милекне биләмәгә һәм (яки) файдалану өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 34);

35. Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару буенча коммерциячел булмаган оешма әгъзасы булган гражданнарга уртак милек булган җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 35);

36. Муниципаль берәмлекнең муниципаль милкен сату үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 36);

37. Килешү төзү хокукын алу буенча үткәрелә торган сату-алу нәтиҗәләре буенча муниципаль милек белән түләүсез файдалану килешүе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 37);

38. Объектның урнашу урынын алдан килештерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 38);

39. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга шәхси милеккә (арендага) индивидуаль торак төзелеше өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 39);

40. Муниципаль милекне арендалау буенча гамәлдә булган килешүне өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта № 40).

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2016 ел, 1768 нче санлы карарын, “Муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын ралау турында”, 30.11.2015 ел, 1038 нче санлы карары белән расланган 14, 15, 16, 17, 18, 19, 20, 21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 28, 29, 30, 31, 32, 33, 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42,43, 44, 45, 46, 47, 48, 49, 50, 51, 52, 53 нче санлы кушымталарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов